ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.05.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1419**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 2 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 1780 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 2 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 1780 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә.

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 35 800 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 34 200 |
| Бүлек башлыгы | 28 500 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 25 000 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 24 800 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 24 800 |
| Сатып алулар өлкәсендә әйдәп баручы белгеч | 24 800 |
| Әйдәп баручы ревизор | 24 800 |
| Хисапчы | 23 300 |

| | |
|---|---|
| Ревизор | 23 300 |
| Сатып алулар өлкәсендә белгеч | 23 300»; |

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 2 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 2 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 1780 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында »(Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 02 октябрендәге 1886 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) 3424 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин